ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30 октябрь, 2024 ел № 37/11

Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, «Россия Федерациясе Урман кодексына һәм Россия Федерациясе Җир кодексының 98 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 августындагы 486-ФЗ номерлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде

1. Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә (Шәһәр Советының 2018 елның 10 августындагы 26/11, 2019 елның 25 февралендәге 30/6, 2019 елның 1 августындагы 32/11, 2020 елның 17 июнендәге 40/6, 2021 елның 18 мартындагы 6/12, 2021 елның 3 ноябрендәге 9/9, 2022 елның 23 июнендәге 15/10, 2023 елның 29 июнендәге 25/10 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 6 пунктта 1, 30, 46 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) территорияне төзекләндерү - муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрендә билгеләнгән гражданнарның яшәү шартларының уңайлылыгын тәэмин итүгә һәм арттыруга, муниципаль берәмлек территориясенең санитар һәм эстетик торышын саклау һәм яхшыртуга, торак пунктлар территорияләрен һәм мондый территорияләрдә урнашкан объектларны, шул исәптән гомуми файдаланудагы территорияләрне, җир участокларын, биналарны, корылмаларны, төзелмәләрне, янәшәдәге территорияләрне карап тотуга юнәлдерелгән чаралар комплексын гамәлгә ашыру;

30) яшелләндерелгән территорияләр - ясалма төзелгән бакча-парк

комплекслары һәм объектлары, бульварлар, скверлар, газоннар, чәчәклекләр, торак, иҗтимагый, эшлекле, коммуналь, җитештерү билгеләнешендәге аз төзелешле территория, табигый үсемлекләр биләгән җир участоклары;

46) рекреация билгеләнешендәге җирләр - рекреацион эшчәнлекне гамәлгә ашыру (туризм, физик культура һәм спорт, гражданнарның ялын оештыру һәм сәламәтлеген ныгыту өлкәсендә эшләр башкару һәм хезмәт күрсәтү) өчен файдаланыла торган җирләр.»;

2) түбәндәге эчтәлектәге 45.1 пункт өстәргә:

«45.1 Юлларны пычранудан саклау өчен брезент яки башка япма белән капламый туфрак, чүп-чар, коела торган төзелеш материалларын, җиңел тараны, агач түмәрләрен, шулай ук юлга, тротуарга, юл кырыена яисә юл янындагы газон полосасына коймыйча ташу чараларын күрмичә төзелеш катнашмаларын һәм эремәләрне (шул исәптән цемент-ком, известь эремәләрен, бетон катнашмаларын) ташу рөхсәт ителми. Өлешчә капланган йөк ташу йөкне капламыйча ташуга тиңләнә».

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыгын үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш.Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев